Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 октябрь 2022 ел №17

Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы башкарма комитетының 2021 елның 8 июнендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау турында” гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2022 елның 15 сентябрендәге 02-08-02/293-2022 номерлы протестын карап

Ямаш авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы башкарма комитетының 2021 елның 8 июнендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

3.2 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.2.Яшәү урыны яисә килү урыны буенча (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) килү урыны буенча теркәлү белән расланмаган гражданнарны яисә альтернатив граждан хезмәте узу урынын Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясе Хекүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгы тарафыннан эшләнә торган методик тәкъдимнәр белән расланган хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмә нигезендә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыра. Беренчел хәрби исәпкә алу торышы өчен җирлек башкарма комитеты җитәкчесе җавап бирә.»

карарга 2 нче кушымтада:

өченче абзацны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«-яшәү урыны яисә килү урыны буенча (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) килү урыны буенча теркәлү белән расланмаган гражданнарны яисә альтернатив граждан хезмәте узу урынын Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясе Хекүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгы тарафыннан эшләнә торган методик тәкъдимнәр белән расланган

хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмә нигезендә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыра.»

унберенче абзацны киләсе редакциядә бәян итәргә:

Хәрби билетларның (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлы таныклыкларның) барлыгын һәм дөреслеген, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның билетлары яисә таныклыклары урынына белешмәләрне, шулай ук аларда язмаларның дереслеген, мобилизация күрсәтмәләре булуын (хәрби билетларда яисә хәрби билетлар урынына бирелгән тамгалар урынына хәрбиләр өчен билгеләнгән очракларда яисә белешмәләрдә аларны тапшыру турында тамгалар булу), гражданнарны элекке яшәү урыны буенча хәрби исәпкә алу турында хәрби исәп документларындагы билгеләр, Россия Федерациясе гражданнары паспортларында аларның хәрби бурычларына мөнәсәбәте турында билгеләр, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең шәхси номерлары булган жетоннарны (хәрби билетларда аларны тапшыру турында билгеләр булганда хәрби бурычлылар өчен) тикшерәләр.

уникенчедән башлап унбишенчегә кадәр абзацларны төшереп калдырырга;

уналтынчыдан башлап кырык тугызынчыга кадәр абзацларны уникенчедән башлап кырык бишенче абзацлар дип санарга;

егерменчедән башлап егерме икенчегә кадәр абзацларны киләсе редакциядән бәян итәргә:

«Запас офицерларына беренчел исәпкә алу карточкаларын тутыралар.

Прапорщикларга, мичманнарга, старшиналарга, сержантларга, солдатларга һәм запас матросларга алфавит карточкаларын һәм хисап карточкаларын тутыралар (2 нөсхәдә). Хәрби хезмәткә чакырылучыларны беренчел хәрби исәпкә алу карталарын тутыралар. Күрсәтелгән документларны тутыру хәрби билетлардагы язмалар (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыклар), хәрби билетлар урынына белешмәләр һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыклары нигезендә башкарыла.

Шул ук вакытта гражданнарның, шул исәптән яшәү урыны һәм (яки) тору урыны буенча теркәлү белән расланмаганнарның гаилә хәле, белеме, эш урыны (уку), вазыйфасы, яшәү урыны яки тору урыны турында белешмәләр һәм хәрби исәпкә алына торган гражданнарның документларындагы башка кирәкле белешмәләр төгәлләштерелә.».

2. Әлеге карарны Ямаш авылы, Совет урамы, 109а йорты; Зәй-Чишмә авылы, Верхняя урамы, 18б нчы йорт; Березовка авылы, Үзәк урам, 10 нчы йорт, Нолинка авылы, Лесная урамы,3 нчы йорт, Петровка бистәсе, Үзәк урамы, 10 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Ямаш авылы башкарма комитеты җитәкчесе — Е.С.Ларин